| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.11.2022 Казан ш № 1039

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 12 ноябрендәге 831 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 12 ноябрендәге 831 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 04.02.2016 №61, 11.12.2017 №863, 16.07.2018 №561, 12.10.2018№938, 20.05.2019 №380, 14.11.2019 №1024, 29.06.2020 №464, 28.09.2020 №672, 17.11.2021 №847 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.А. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 21.11.2022 ел, №1039 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 12 ноябрендәге 831 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәрләрендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль яклау идарәләре (бүлекләре) башлыкларына әлеге Регламент нигезләмәләренең тайпылышсыз үтәлүен тәэмин итәргә.»;

әлеге боерык белән расланган Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1 бүлектә:

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) мөрәҗәгать итүченең профилен яңасына үзгәртү үткәрелми.»;

1.3.1 – 1.5 пунктларны көчен югалткан дип танырга;

2-4 бүлекләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы

Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме

2.2.1. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яисә шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) исеменнән Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин

итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – территориаль органнар) тарафыннан күрсәтелә.

2.2.2. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә (алга таба – КФҮ) дәүләт хезмәте күрсәтелми.

## 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булып гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында телдән яисә язма рәвештә (мәгълүмати хат) социаль хезмәт күрсәтүчеләр тарафыннан мәгълүмат бирү тора.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарткан очракта, мөрәҗәгать итүчегә баш тартуның сәбәбен күрсәтеп хат җибәрелә (алга таба – мәгълүмат бирүдән баш тарту турында хат).

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә, хәбәр ителә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

электрон документ формасында мөрәҗәгать итүченең «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасындагы (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) шәхси кабинетына җибәреп яки электрон почта аша;

шәхсән мөрәҗәгать иткәндә телдән.

## 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Шәхсән телдән, шул исәптән телефон аша, мөрәҗәгать иткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты 10 минуттан артмаска тиеш.

Шәхсән телдән мөрәҗәгать иткәндә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

2.4.2. Язма мөрәҗәгать иткәндә, почта аша, электрон почта аша дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы гариза теркәлгән көннән алып сигез эш көненнән артмый.

2.4.3. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинеты аша мөрәҗәгать иткәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында чагылдырыла торган «Документларны тикшерү» статусы һәм эшләр номенклатурасы нигезендә гаризага номер бирелгән көннән башлап сигез эш көненнән артыграк түгел.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында (алга таба – Бердәм портал), Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http://uslugi.tatarstan.ru/) урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

## 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен мөрәҗәгать итүче язмача мөрәҗәгать иткән очракта, әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү хакында дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны (алга таба - гариза) тапшыра.

2.6.2. Гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча җибәрелә ала:

шәхсән яисә почта аша кәгазьдә;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинет аша гариза формасын тутыру юлы белән Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада;

гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша (алга таба - «Интернет» челтәре) 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә.

Гаризаны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша җибәргән очракта, гариза «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланырга (расланган булырга) тиеш.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалый.

Гади электрон имза алу өчен мөрәҗәгать итүчегә электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик багланышларын тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасында (алга таба – бердәм система) теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын да расларга кирәк.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагында булган документларны тапшыру таләп ителми.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр юк.

### 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

Язмача мөрәҗәгать иткәндә, шул исәптән электрон документ формасында, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешенчә рәсмиләштерелмәгән гариза тапшыруы (тутырылмаган реквизитлар булуы – мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) яки оешма атамасы, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе җибәрелергә мөмкин почта адресы, электрон почта адресы, гариזаның тексты укылышлы булмаса).

2.8.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәтен күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Интернет» мәгълүмат-телекумуция челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) (http://mtsz.tatarstan.ru) басылып чыккан мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.8.3. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

### 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

### 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәләрен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.10.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен кабул итүне көтү буенча чират билгеләнмәгән.

### 2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза алынган көнендә теркәлә.

2.11.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы ял (бәйрәм) көне булып саналмаган эш көнендә, ә гариза эш көне тәмамланганнан соң алынган очракта, икенче эш көнендә теркәлә.

2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән хезмәт күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чykканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектлардан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән хезмәттән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, хезмәтләр күрсәтелә торган объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, хезмәтләрдән файдалана алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) территориаль органнарның белгечләре тарафыннан инвалидларга хезмәт күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, хезмәт күрсәтү;

в) территориаль органнарның хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен комачау иткән каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

территориаль органнар биналарының җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкинлеге булган зонада урнашуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булуы;

гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;

дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтелүе.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

территориаль органнарның белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы.

мөрәҗәгать итүченең территориаль органнар белгечләре белән хезмәттәшлек итү саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури гаризаны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең территориаль органнар белгечләре белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итү вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.

2.13.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк аша гамәлгә ашырылмый.

2.13.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан алынырга мөмкин.

2.13.6. Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

## 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.2. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирергә;

в) гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алырга;

г) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы

порталы ярдәмендә территориаль орган, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.3. Гаризаны формалаштыру Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән формалаштырыла. Бу очракта мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында БИАС системасында исәпкә алыну язуын раслау юлы белән авторизация уза, электрон рәвештә интерактив формадан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тутыра.

2.14.4. Мәгълүмат хаты яисә мәгълүмат бирүдән баш тарту турындагы хат мөрәҗәгать итүчегә, мөрәҗәгать итүченең вәкиленә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетка территориаль орган җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

2.14.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында тутырылган гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан территориаль органнарга җибәрелә. БИАС системасында авторизацияләнгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза мөрәҗәгать итүченең, гаризаны имзалау өчен вәкаләтле мөрәҗәгать итүче вәкиленең гади электрон имзасы белән имзаланган дип санала.

2.14.6. Мөрәҗәгать итүчеләрне территориаль органнарга кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, территориаль органнарның телефон номеры аша телефон элемтәсе аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә вәкаләтле органнарда билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итү көннәре, вакыты һәм урыннары.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу барышында күрсәтелгән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылган вакытта, мөрәҗәгать итүчегә үзе тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән, әгәр дә ул кабул итү өчен билгеләнгән вакыттан соң 15 минут узгач килмәсә, алдан язылуның гамәлдән чыгарылачагы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яки территориаль органнарның телефон номеры буенча алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

2.14.7. Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын

күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.14.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләр эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:
1) мөрәҗәгать итүчегә консультацияләр бирү;
2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гаризаны кабул итү һәм карау;
3) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү;
4) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү);
5) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм ялгышларны төзәтү (алга таба – техник хата).

3.2. Мөрәҗәгать итүчене, шул исәптән дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле гаризаның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә консультацияләү мөрәҗәгать итүче территориаль органга килгәндә территориаль орган белгече тарафыннан телдән (шул исәптән телефон аша) гамәлгә ашыра.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла. Административ процедураларның озынлыгы шәхсән мөрәҗәгать иткәндә консультацияли башлау вакытыннан башлап 10 минуттан һәм телефон аша сөйләшә башлаган вакыттан башлап 10 минуттан артып китәргә тиеш түгел.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: дәүләт хезмәтен алу өчен кирәкле гаризаның составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны төзү өлешендә дә.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән яисә телефон аша территориаль органга мөрәҗәгать итә.

Мөрәҗәгать итүче территориаль органга дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап шәхсән телдән, шул исәптән телефон аша мөрәҗәгать иткәндә, территориаль орган белгече:

мөрәҗәгать итүченең шәхесен (фамилиясен, исемен, атасының исемен (соңгысы – булган очракта)) билгели;

телдән мөрәҗәгатьне гаризаларны теркәү журналында терки;

Социаль хезмәтләр күрсәтү белән тәэмин итүчеләр тарафыннан гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында телдән мәгълүмат бирә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла. Административ процедураларның озынлыгы

шәхсән мөрәҗәгать иткәндә консультацияли башлау вакытыннан башлап 10 минуттан һәм телефон аша сөйләшә башлаган вакыттан башлап 10 минуттан артып китәргә тиеш түгел.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында телдән яисә язма рәвештә социаль хезмәт күрсәтүчеләр тарафыннан мәгълүмат бирү.

3.3.2. Мөрәҗәгать итүче территориаль органга гариза тапшыра.

Гариза шәхсән тапшырылырга, почта элемтәсе оешмалары аша җибәрелергә мөмкин.

Электрон документ рәвешендә җибәрелә торган гариза 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә имзалана һәм электрон чыганаклардан файдаланып һәм (яки) Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша территориаль органга тапшырыла.

Гаризаны формалаштырганда мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) гаризаның күчермәсен алу һәм саклау мөмкинлеге;

б) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

в) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

г) БИАС булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә, БИАС системасында урнаштырылган һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр электрон гариза формасы кырларын тутыру;

д) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

е) мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында бер елдан азрак булмаган чорда үзе элегрәк тапшырган гаризаларны, шулай ук кимендә 3 ай эчендә өлешчә формалаштырган гаризаларны карау мөмкинлеге.

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша почта аша яисә электрон документ рәвешендә тапшырылган гариза әлеге Регламентның 3.3 пункты нигезендә карала.

Территориаль орган белгече гаризаны гаризаларны теркәү журналында терки һәм әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең булу-булмавын тикшерә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булган очракта, территориаль орган белгече мөрәҗәгать итүчегә, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрне күрсәтеп, мәгълүмат бирүдән баш тарту турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла. Электрон гариза ял (бәйрәм) көнендә килгән очракта – ял (бәйрәм) көненнән соң

икенче эш көнендә.

Административ процедураларның нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора: әлеге Регламентка 5 нче кушымта нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаларны теркәү журналында теркәү язуы.

3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү

3.4.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булмаган очракта, территориаль орган белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мәгълүмат хаты проектын рәсмиләштерә;

мәгълүмат хаты проектын имзалау өчен территориаль орган җитәкчесенә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.3.2 пунктында каралган процедуралар тәмамланган көннән биш эш көнендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларның нәтиҗәсе булып мәгълүмат хаты проекты тора.

Гаризаны (шәхсән мөрәҗәгать иткәндә) кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, территориаль орган белгече мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булуы турында телдән хәбәр итә һәм, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, гаризаны кире кайтара. Гаризаны почта һәм (яисә) «Интернет» челтәре аша алганда, территориаль орган белгече гаризаны кабул итүдән һәм теркәүдән баш тарту сәбәпләрен аңлатып, хат проектын рәсмиләштерә.

Административ процедураларның нәтиҗәсе булып мәгълүмат хаты яки мәгълүмат бирүдән баш тарту турында хат проекты тора.

3.4.2. Мәгълүмат хаты (яки мәгълүмат бирүдән баш тарту турында хат) проектын караганнан соң, территориаль орган җитәкчесе аны имзалый һәм территориаль орган белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мәгълүмат хаты (мәгълүмат бирүдән баш тарту турында хат) проекты имзалау өчен җибәрелгән көннән алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе – территориаль орган җитәкчесе кул куйган мәгълүмат хаты (мәгълүмат бирүдән баш тарту турында хат).

3.5. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

Территориаль орган белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән мәгълүмат хатын (яисә мәгълүмат бирүдән баш тарту турында хат) җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында каралган процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе – мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән мәгълүмат хаты (мәгълүмат бирүдән баш тарту турында хат).

3.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм ялгышларны төзәтү (алга таба – техник хата).

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 3 нче кушымтасына

ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.

3.7.1. Территориаль орган белгече:

техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм әлеге Регламентка 4 нче кушымта нигезендә техник хатаны төзәтү турында гаризаларны теркәү журналында терки;

мәгълүмат хаты проектын үзгәртеп рәсмиләштерә;

үзгәртеп рәсмиләштерелгән мәгълүмат хаты проектын имзалау өчен территориаль орган җитәкчесенә юллый.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларның нәтиҗәсе булып техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, территориаль орган җитәкчесенә имзалау өчен юнәлдерелгән үзгәртеп рәсмиләштерелгән мәгълүмат хаты проекты тора.

3.7.2. Территориаль орган җитәкчесе үзгәртеп рәсмиләштерелгән мәгълүмат хатын имзалый һәм аны территориаль орган белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура мәгълүмат хаты имза салу өчен җибәрелгән вакыттан башлап ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып имзаланган мәгълүмати хаты тора.

3.7.3. Территориаль орган белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән үзгәртеп рәсмиләштерелгән мәгълүмат хатын җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура әлеге Регламентның 3.7.2 пунктта каралган процедура тәмамланган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып мөрәҗәгать итүчегә җибәрелгән үзгәртеп рәсмиләштерелгән мәгълүмат хаты тора.

4. Административ регламент үтәлешен контрольдә тоту формалары

4.1. Регламент процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге саклануны даими рәвештә тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган территориаль органнарның җитәкчеләре тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлүенә һәм башкарылуына тикшерүләр үткәрү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшереп тору территориаль органнар җитәкчеләре тарафыннан гамәлгә ашырыла, аларның вәкаләтләре территориаль органнар җитәкчеләренең вазыйфаи регламентлары белән билгеләнә.

Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.

4.3. Агымдагы контрольлек Министрлыктагы вазыйфаи затларның әлеге регламентта һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актлардагы нигезләмәләрне үтәвенә һәм башкаруына тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы тикшереп тору даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.4. Әлеге Регламент үтәлешен контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләргә тикшерүләр үткәрүне, карарлар кабул итүне, җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.5. Әлеге Регламент үтәлешенә планнан тыш тикшерү уздыру турындагы карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламенттагы һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгеле торган норматив хокукый актлардагы таләпләрне бозуның элек ачыкланган очракларын юкка чыгаруны тикшерүгә бәйле рәвештә;

2) мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган вазыйфаи затлары гамәлләренең (гамәл кылмавының) үзләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга бәйле шикаятьләр белән мөрәҗәгать иткәндә.

4.6. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозу очраклары ачыкланган очракта, әлеге административ регламентны үтәү өчен җаваплы булып, гаепле дип танылган вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан әлеге Регламент үтәлешен тикшерүдә тоту дәүләт хезмәте күрсәткәндә территориаль органнар аша Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү эшчәнлегендә мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.»;

5 бүлектә:

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, КФҮ, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр территориаль орган карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр тәртиптә территориаль орган җитәкчесенә

шикаять белдерү хокукына ия.

Территориаль орган җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка министр исеменә тапшырыла.»;

5.2 пунктта:

1 пунктчада «дәүләт хезмәте» сүзләреннән соң «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән гариза» сүзләрен өстәргә;

7 пунктчада «дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның (оешманың), органдагы вазыйфаи затның (белгечнең)» сүзләрен «дәүләт хезмәтен күрсәтә торган территориаль органның, территориаль орган белгеченең» сүзләренә алмаштырырга;

5.3 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче территориаль органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче территориаль орган белгеченең, дәүләт хезмәте күрсәтүче территориаль органның дәүләт хезмәткәренең, җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.»;

5.4 пунктның өченче абзацында «органның (оешманың)» сүзләрен «территориаль органның» сүзләренә алмаштырырга;

5.5 пунктта:

1 пунктчада «дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның (оешманың), органдагы вазыйфаи затның (белгечнең)» сүзләрен «дәүләт хезмәтен күрсәтә торган территориаль органның, территориаль орган белгеченең» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктчада «дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның (оешманың), органдагы (оешмадагы) вазыйфаи затның (белгечнең)» сүзләрен «дәүләт хезмәтен күрсәтә торган территориаль органның, территориаль орган белгеченең» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктчада «дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның (оешманың), органдагы (оешмадагы) вазыйфаи затның (белгечнең)» сүзләрен «дәүләт хезмәтен күрсәтә торган территориаль органның, территориаль орган белгеченең» сүзләренә алмаштырырга;

5.7 пунктта «орган (оешма)» сүзләрен «территориаль орган» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка 1 нчы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү<br>өлкәсендә социаль хезмәтләр белән<br>тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль<br>хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында<br>мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте<br>күрсәтүнең административ регламентына<br>1 нче кушымта

киңәш ителә торган рәвеше

Кайда ____________________________________________________________

*(дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче органның (оешманың) атамасы)*

кемнән ____________________________________________________________,
*(гражданинның ФИА тулысынча)*

теркәлгән адрес: ______________________________________________________
*(күрсәтергә кирәк: индекс, РФ субъекты, шәһәр (авыл, поселок, сала), урам, йорт һәм фатир номеры)*

яши торган адрес: _____________________________________________________
*(күрсәтергә кирәк: индекс, РФ субъекты, шәһәр (авыл, поселок, сала), урам, йорт һәм фатир номеры)*

Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза

Мәсьәлә буенча мәгълүматны түбәндәгечә бирүегезне сорыйм __________
__________________________________________________________________
__________________________________________________________________.

Мәгълүматлар алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында, риза:

язма рәвештә – шәхсән яки почта адресы буенча ______________________

электрон документ формасында электрон почта адресы буенча __________

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша.

Регламентка 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү
өлкәсендә социаль хезмәтләр белән тәэмин
итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр
күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 3 нче кушымта

Җитәкчегә

________________________________
*(дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче орган атамасы)*

________________________________

________________________________

Кемнән: _________________________

________________________________

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин, _______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)

яши торган адрес: ____________________________________

__________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)

__________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документның аталышы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы, документны биргән органның аталышы)

_______________________________________________________________

техник хатаны төзәтүне сорыйм ______________________________________

___________ №_____________ мәгълүмат хатында җибәрелгән.

Мәгълүматлар алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында, риза:

язма рәвештә – шәхсән яки почта адресы буенча ____________________

электрон документ формасында электрон почта адресы буенча __________

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша.

«__» __________ 20__ ел.

_____________________ ____________________________»;

*(мөрәҗәгать итүченең имзасы)* *(тулы имза)*

Регламентка кушымтаны (белешмәлекне) үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле 5 нче кушымта өстәргә:

«Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү
өлкәсендә социаль хезмәтләр белән
тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль
хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында
мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте
күрсәтүнең административ
регламентына 5 нче кушымта

Гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаларны теркәү журналы

| Номер (№) | Телдән мөрәҗәгать не яки гаризаны теркәү датасы | Мөрәҗәгать итүченең ФИА (оешма атамасы) | Мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысулы (телдән, датасын һәм номерын күрсәтеп, мәгълүмат хаты) | | Социаль яклау органы белгече имзасы». |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | телдән мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүченең яисә аның законлы вәкиленең имзасы | язмача мөрәҗәгать иткәндә мәгълүмат хаты (датасы, номеры) | |
| | | | | | |